

21 август конне педагогик хезмәткәрләрнен һонәри осталыгын озлексез кvтәрv vзәге «Педагог 13.ру»да «Гаилә һәм мәктәп: тәрбия мәгънәләре һәм кыйммәтләре бердәмлеге» республика педагогик форумы - 2024 кысаларында vткән «Туган телләрне һәм милли мәдәниятне саклауда гаилә һәм мәктәп роле» методик мәйданчыгында педагогик практикалар һәм идеяләр белән Мордовиянен туган тел, шул исәптән татар теле һәм әдәбияты укытучылары уртаклаштылар. «Педагог 13.ру»да татар теле һәм әдәбияты укытучыларына методик ярдәм итvче методист, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбендә ана телен укытучы Боярова Фазия Фәрит кызы, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Саляева Сания Спартак кызы, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбендә ана теленә ойрәтvче Юмаева Равза Мукаддяс кызы, быел регионара татар теле һәм әдәбияты укытучылары конкурсында жинv яулаган Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Кильдеева Зәйнәб Хосәен кызы әлеге чарада катнаштылар. Алар бу жыелышта олы тәжрибәләре белән уртаклаштылар, башкаларнын яналыкларын эшләрендә кулланырга дип тупладылар.

Чарада заманча укыту дәресе, гаилә туризмы очен белем бирv маршрутлары дигән яналыкларны ишеттеләр һәм «Гаиләдә телне саклыйк» Мордовия һәм Ботенроссия конкурсларында жинvче педагоглар биргән мастер-классларда катнаштылар.